## **Галиева Гөлсирин апа (1944 елда туган) сөйләгәннәрдән**

***(музей материалларыннан алынды.Ул 2016 елда безнең арадан китте)***

Без бала чакта 9 яшь тулгач – өченче сыйныф – 22 апрельдә, бөтен дружина сборында тантаналы рәвештә пионерга кабул итү церемониясе уза иде.

Май аенда тагын бер бәйрәмне– пионерлар көнен билгеләп үтә идек. 19 майда бөтен укучылар белән Пионер аланына экскурсиягә бара идек. Анда учаклар ягып, уеннар уйнап, рәхәтләнеп күңел ачып кайта идек.

Нык безнең адым, йөрәкләр кайнар. Бу юллар — элек пионерлар яратып җырлый торган тимурчылар җырыннан.Мәктәптә тимурчылар отряды эшли иде. Уку елы башында ярдәмгә мохтаҗларның исемлеге төзелеп, аларга пионерлар һәм комсомоллар беркетелә. Мактау һәм бүләк өмет итмичә, үзебез дә куанып, кешеләрне дә шатландырып, тыйнак кына, тыныч кына эшли идек.

Урманасты Шынталысы